ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл
җирлеге Советы

422743, ТР Әтнә муниципаль районы,
Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а

тел. 33-4-05, тел./факс 33-4-03

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Нижнебереskинского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422743, РТ, Атнинский муниципальный
район, село Нижняя Береске, улица
Совета, д. 17а
тел. 33-4-05, тел./факс 33-4-03

**КАРАР**

3 ноябрь 2022 ел № 4

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге
Олы Өшкәтә торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Уставы нигезендә, **карар бирәм:**

1. 2022 елның 16 ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Өшкәтә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Өшкәтә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 16 ноябрь 2022 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны – Олы Өшкәтә авылы, Большая урамы, 21А йорт адресы буенча урнашкан ФАП янында.

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетына тәкъдим итергә:

- 2022 елның 9 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а йорт;
- сайлау хокукына ия булган Олы Өшкәтә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Олы Өшкәтә торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Өшкәтә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Олы Өшкәтә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куаклар кисү);

2) Олы Өшкәтә авылы зиратының коймасын эшләү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм ТР Әтнә муниципаль районы, Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а йорт адресы буенча урнашкан Түбән Бәрәскә авыл җирлеге бинасында мәгълүмат стендында; ТР Әтнә муниципаль районы, Олы Өшкәтә авылы, Большая урамы, 21а йорт, ФАП бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге җитәкчесе: Фатыхова А.В.